
Бүгенге санда:



Төзүчеләр төзи, ГИСУ тикшерә. 2 бит.


# Дуслык
Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Җомга 23 гыйнвар 2015 ел

№ 4 (10533)


**24 гыйнварга һава торышы:** аязучан болытлы һава; юнәлеше үзгәрүчән җил, 3-4 м/с; температура көндез -21°С, төнлә -20°С

## *Абзац-информ*

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

### ХАТЫН-КЫЗЛАР КОНКУРСКА ӘЗЕРЛӘНӘ

"Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз күзлегеннән" республика конкурсының район турында катнашачак кандидатлар исемлеге 21 гыйнварда район хатын-кызлар советы каршында узган утырышта төгәлләштерелде. Җиңүчеләр февральнең 18ендә зона турында район данын яклаячаклар. Оештыру комитеты катнашучыларның төрле тармактан, төрле җирлекләрдән булуына игътибар итте һәм аларның социаль һәм иҗтимагый активлыкларына өстенлек бирде.

### ҖЫЕННАР ДӘВАМ ИТӘ

Авылларда гражданнар җыеннары дәвам итә. Кичә алар Колбай Мораса, Әмзә, Иске Әлмәт, Кычытканлы һәм Сәләнгеш авыл җирлекләрендә үтте.

### ТӘКЪДИР ИТҮДӘ КАТНАШТЫЛАР

Бу атнада районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе белгечләре, хуҗалык җитәкчеләре һәм инженерлары республика авыл хуҗалыгы техникасын һәм җайланмаларын тәкъдир итү чарасында катнашып кайттылар. "Татагролизинг" җәмгыяте базасында үткән әлеге гамәли семинарда белгечләр яңа техника һәм җайланмалар белән танышып кына калмаганнар, җитештерүче завод белгечләре белән аралашып, техниканың мөмкинлекләре, аларны эксплуатацияләү һәм хезмәт күрсәтү үзенчәлекләре турында да күп яңалык алганнар.

### ЯҢА ҖИҺАЗЛАР КАЙТТЫ

Нурлат картлар һәм инвалидлар интернат-йортында яшәүчеләр ел башыннан сәламәтлекләрен 1 миллион ярымлык махсус тернәкләндерү җиһазларында ныгыталар. Интернат-йортның дәвалау физкультурасы кабинетында урнаштырылган заманча җиһазларда мөмкинлекләре чикләнгән һәркемгә шөгыльләнү өчен аерым программа каралган.

# Яшьлекнең гүзәл бәйрәме

**25 гыйнварда илебездә Татьяналар көне, ягъни Студентлар бәйрәме билгеләп үтелә.**



З.Әксанова фотосы

Бәйрәмнең тарихы тамырлары белән еракларга барып тоташса да, аны билгеләп үтү йолалары безнең көннәргә кадәр сакланган. Моннан йөз ел элек студентлар күңел ачу мәҗлесләре оештырган булсалар, хәзер дә яшьләр әлеге бәйрәмне бик мавыктыргыч итеп үткәрә.

Бу көннәрдә Нурлатның күпчелек студенты каникулларда. Әнә, КФУда юридик факультетта белем алучы Екатерина Граф, Санкт-Петербург дәүләт икътисад университеты студенткасы Эвелина Атауллина һәм КФУның I курсында укучы Алия Яруллина бу бәйрәмне көтеп алалар икән.

– Бу көннең каникулларга туры килүе икеләтә сөенечле, – диләр студентлар беравыздан. – Дус-ишләр, әти-әниләр, яраткан шәһәребез белән күрешү, яңа семестрга көч туплау чоры да бит әле ул. Әлбәттә, сыйныфташлар белән очрашу вакыты да. Кайчандыр үзебез укыган 2нче урта мәктәптә әлеге дата уңаеннан ел да төрле чаралар оештырыла. Студентлар кичәсе аеруча җанлы үтә.

Ә Нурлат яшьләре әлеге датаны быел пейнтбол ярышлары белән дә истә калдырмакчы икән. Гыйнварның соңгы якшәмбесендә "Чияле Алан" ял базасы территориясендә узачак ярышларда районның нефть-газ оешмалары, "Бердәм Россия" җирле бүлекчәсе һәм район башкарма комитетының җыелма командалары очрашачак.

**Зилия ӘКСАНОВА**

ТЕЛДӘН-ТЕЛГӘ

# Мәеткә дә белешмә кирәк

**1 февральдән мәетне җирләү өчен шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетларыннан белешмә кирәк булачак. Бу хактагы яңалык газетабызның рәсми сайтында дөнья күргәннән соң, социаль челтәрдәге төркемнәрдә күпләр үз фикерен белдерергә ашыкты.**

**Шуларның кайберләре:**

- *"Үләргә дә куркыныч, туганнар өчен күпме проблема"*
- *"Кеше үлгәч, болай да кайгы. Өстәвенә, күпме кабинетлар узасы һәм кәгазьләр җыясы!"*
- *"Акча эшләү буенча чираттагы афера бу!"*
- *"Әгәр шимбә-якшәмбе, я булмаса каникуллар чорына туры килсә?",*
- *"Хәзер бала табу, кеше үлү дә башкарма комитет аша башкарылачакмы?"*
- *"Башкарма комитет рөхсәт бирмәсә, мәет икешәр атна күмелмәячәкме?*
- *Әлеге "закон"ның инициаторы кем? Белешмәләр - чираттагы акча җыюмы?"*

Бу сорауларга 16 гыйнварда полиция, район үзәк хастаханәсе, ЗАГС бүлекләре һәм зират караучылары катнашында шәһәр башкарма комитетында җирләү эше турындагы мәсьәләгә багышлап уздырылган киңәшмәдә ачыклык кертелде.

- Бар да закон нигезендә эшләнә, - ди шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Венера Мингалиева. – Иң элек, кешенең үлеме теркәлергә тиеш. Моны, билгеле, табиблар башкара. Әгәр кеше хастаханәдә үлә икән, барлык документлар анда эшләнә. Кеше өйдә үлсә, поликлиникага 2–27–06 номерына яки "ашыгыч ярдәм" службасына шалтыратырга кирәк. Икенче адым – ЗАГС бүлегеннән үлем турындагы таныклык алу. Ул ЗАГС бүлегендә мәрхүмнең медицина белешмәсе һәм паспорты нигезендә бирелә. ЗАГС бүлегенә 2–06–25 телефонына шалтыратырга кирәк. Өченче адым – шәһәр яки авыл җирлеге башкарма комитетыннан белешмә алу. Шәһәр башкарма комитетының телефоны: 2–06–85. Һәр өч учреждениедән дә белешмәләр түләүсез бирелә, моннан тыш, һәр алда телгә алган службалар шимбә-якшәмбе һәм каникуллар булуына карамастан эшлиләр.

(Ахыры 2нче биттә)

*Газетага язылырга оныттыгызмы? Хәзер язылсагыз, сезгә ул февральдән килә башлар.*

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

ИНФРАСТРУКТУРА

## *Марат Айзатуллин:* “Төзүчеләрдә шигем юк”

**Район һәм шәһәрдәге кайбер төзелеш һәм капиталь ремонт объектларын чәршәмбе көнне республиканың ГИСУ директоры Марат Айзатуллин карап чыкты.**

Эш визиты Нурлат районы башлыгы Равил Кузюров озатуында Каравыл Тавындагы күпфункцияле үзәктәге төзелеш барышын караудан башланды. Объектның подрядчысы – “ГородСтрой” җәмгыяте. Төзүчеләр бу атнада стеналарны азагына кадәр өеп бетерәчәкбез, дип ышандырдылар, киләсе этап – түбә, ә мартта газ бирәчәкләр. МФЦда китапханә дә урнашыр, дип планлаштыралар, шулай ук мини-спорт залы да булачак.

Маршруттагы чираттагы нокта шәһәрнең Төньяк-Көнчыгыш микрорайонында төзелүче балалар бакчасы иде. Район башлыгы объектның подрядчысы “ПИК+” җәмгыятенә быел башка объектлар буенча да зур йөк төште, әмма төзүчеләр графиктан тайпылмый, дип билгеләп үтте. Марат Мансурович проект, челтәрләр буенча проблемалар юкмы, дип кызыксынды, сметага кагылышлы бар нәрсәне азаккача эшләп бетерергә киңәш бирде. Язгы ташуга кадәр бакчаның стеналарын күтәреп бетерергә, дигән бурыч куелды.

Эш визиты барышында ГИСУ директоры шәһәр өчен мөһим объект – муниципаль мунчада да булды. “Еврострой” башкаручы бүгенге эшләр белән бергәттән, Марат Айзатуллин мунчаның алга таба эшләү мәсьәләсе белән дә кызыксынды. Мисал өчен, халыкка хезмәт күрсәтү җәһәтеннән. Район башлыгы әйтүенчә, сугыш ветераннары өчен мунча бушлай, пенсионерларга ташлама белән булачак. Ә объектны “ТКХ ИК” муниципаль унитар предприятиесе балансына тапшырачаклар.

ГИСУ директорында Халыклар Дуслыгы йортын карау да матур тәэсирләр калдырды. Бүгенге көнгә подрядчы – “Еврострой” җәмгыяте эшләрнең 70 процентын башкарган: пластик тәрәзәләр куелган, электр-монтажлау эшләре башкарылган. Отделка эшләре, фасад һәм җылы бирү калган.

Объектларны карап чыкканнан соң, Марат Айзатуллин үз фикерләрен дә җиткерде:

– Клублар буенча эшләр башкару проценты һәр районда да бу кадәр юк, – диде ул, МФЦ төзелешенә бәя биреп. – Төзүчеләрдә шигем юк: балалар бакчасын да вакытында тапшырырлар дип уйлыйм. Нурлатлылар гомер-гомергә төзелеш ягыннан да, башка тармакларда да башка районнардан аерылып тордылар. Эшләр яхшы дәрәҗәдә бара. Кирәге чыкса, безнең яктан да ярдәм булыр. Нурлатта район җитәкчелегенең нәтиҗәле эше күренә.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**



Автор фотосы

ГИСУ ДИРЕКТОРЫ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ ТӨЗЕЛЕШЕ УҢАЕННАН КАЙБЕР РЕКОМЕНДАЦИЯЛӘР БИРДЕ

## Мәеткә дә белешмә кирәк

*(Ахыры. Башы 1нче биттә)*

1 февральдән кертеләчәк яңалыкның максаты – зиратларда тәртип булдыру. Район һәм шәһәрнең 8 зиратында тикшерү уздырган Монополиягә каршы федераль служба хезмәткәрләре “Күмү һәм җирләү эшләре турында”гы Федераль Законның үтәлешендә кагыйдә бозуларны ачыкладылар. Сер түгел, соңгы вакытта халык мәетләрне үзе теләгән урынга һәм теләсә кемне (мәсәлән, чит шәһәрдән кайтарылганнарны) күмә башлады. Зиратларны карт агач-куаклар басып алды, каберлекләр каралмый, теләсә кайда казылган каберләр аркасында җыештыру өчен техника керә алмый. Шуңа күрә районда күмү һәм җирләү эшләре буенча 1 февральдән кертелгән яңа кагыйдәләр буенча зиратларга агачлар (чыршыдан тыш) утырту тыела. Бары чәчәкләр утырту гына рөхсәт ителәчәк. Әлеге кагыйдәләр республика һәм илебез шәһәрләрендә күптән гамәлдә. Алай гына да түгел, зират өчен җирләрне сатып аласы. Ә бездә җир дә, белешмәләр дә бушлай.

**Зилия ӘКСАНОВА**

ЭШЛЕКЛЕ ДАИРӘ

## Сораулар хәл ителергә тиеш

**Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча сишәмбе көнне үткән ведомствоара комиссия утырышында 2014 елның 13 декабрендәге беркетмәләрнең үтәлешен тикшерделәр. Комиссия утырышы район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин җитәкчелегендә узды.**

Юл билгеләре кую, юлларны һәм тротуарларны кардан чистарту бүгенге көндә актуаль булып кала. Мәсәлән, шәһәрдә бүгенге көндә 250 юл билгесе куелырга тиеш, шуларның 25сен инде бу көннәрдә үк куярга кирәк. Юлларны кардан чистарту алып барылса да, сораулар кала әле. Һәм кар белән томаланган юл чатлары аеруча зур игътибар сорый. Моңа комиссия рәисе дә аерым игътибар юнәлтте, ЮХИДИ начальнигы да хуплады. ТКХ идарәче компаниясе җитәкчесе Фәнис Бакировка кар чистартуга бәйле башка сораулар да булды. Мәсәлән, шәхси секторда юлларны киңәйткәндә (мисалга Дружба урамы китерелде) зур кар көртләрен гаражлар һәм йортлар алдына өеп калдыралар, ә бу җәяүлеләрнең юлларын томалый. Юл читләрендә калдырыла торган автотранспорт – карны яхшылап чистартырга комачаулаучы сәбәпләрнең берсе. ЮХИДИ начальнигы Рөстәм Гарипов әйтүенчә, инде 2 машина штрафстоянкага эвакуацияләнгән. Мондый практика бары тик файдага гына булырга охшаган. Мәсәлән, пик сәгатьләрендә мондый күренешне Совет урамында күзәтергә була, предприятие биналары каршында хезмәткәрләр үз транспортларын тезеп калдыралар.

Тротуарларны чистарту да проблемалы булып кала. Утырыш азагында Әсхәт Касыймович бу уңайдан матур яңалык җиткерде: моның өчен 8 млн. сумга махсус техника – автогрейдер һәм өч МТЗ-82 сатып алыначак.

Урамнарны яктырту – юл хәрәкәте куркынычсызлыгының бер өлеше. Бу уңайдан “ЖилЭнергоСервис” начальнигы Ришат Яруллин һәм шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Нәгыйм Сафиуллинга да сораулар булды. Мәсәлән, бүгенге көндә азык-төлек комбинаты тирәсе проблемалы булып кала. Бүгенге көндә төп сорау 5нче линия булмауга кайтып кала диелсә дә, Әсхәт Касыймович бу урам яктырткычлары урнаштыру мөмкин түгел, дигән сүз түгел, диде. Шәһәрнең кайбер урамнарында сораулары хәл итүнең кыенлыклары бөтенләй баганалар булмауга ук барып тоташа.

Утырышта “Халык инспекторы” мәгълүмати системасына да тукталдылар. Республикада юл хәрәкәте куркынычсызлыгын яхшыртуга корылган яңа системаны әлегә район һәм шәһәр халкы өйрәнеп кенә килә бугай әле. Район башкарма комитетының эшләр идарәчесе Ралия Ханиева әйтүенчә, нурлатлылардан “Халык инспекторы”на хәбәрләр кермәгән әле.

Комиссиядә автомәктәпләр эшчәнлегенә аерым тукталдылар. Бүгенге көндә аларның өчесе рөхсәт алган, берсе – рәсмиләштерү стадиясендә. Утырышта әйтүләренчә, автомәктәпләр даими контрольдә булачак.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

NURLAT-TAT.RU САЙТЫНДА БАШКА КҮП ТӨРЛЕ ХӘБӘРЛӘР УКЫЙ АЛАСЫЗ

ХӘБӘРЛӘР

### МУНЧА ФЕВРАЛЬ АЗАГЫНДА АЧЫЛМАКЧЫ

Район башлыгы Равил Кузюров 20 гыйнварда подрядчы – “Еврострой” ОООсы һәм җаваплы коммуналь службалар җитәкчеләре белән үткәргән киңәшмәдә куелган срокка объектны өлгертү мәсьәләсен кабыргасы белән куйды. Ачыклангaнча, төзелештә җылылык, ут, су үткәрү эшләре үтәлгән, газ службасы өчен башкарма документларны тапшыру да бүген-иртәгә башкарылачак.

– Эштә тоткарлык булмаска тиеш, бу – социаль объект,– диде район башлыгы кабат сроклар турында искәртеп.

**Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА**

### ҮСМЕРЛӘР ЕЛ ӘЙЛӘНӘСЕ ЭШЛИ АЛА

Быел халыкның мәшгульлеге үзәге аша 240 яшүсмерне эшкә урнаштыру планлаштырыла. Алдагы еллардан аермалы буларак, үсмерләргә быел эшкә урнашу өчен каникулларны көтеп тору кирәкми, алар ел әйләнәсе эшли алачак.

– Теләүчеләр инде гыйнвар аеннан ук дәресләрдән соңгы буш вакытларын эшләп, файдалы итеп үткәрә алалар, - ди үзәкнең өлкән инспекторы Рушания Сафина. – Үсмерләр төрле оешма-предприятиеләрдә бик авыр булмаган хезмәттә, мәсәлән, территорияне кардан арындыру, шугалакларны чистарту кебек эшләрдә катнашырга мөмкин. Бу уңайдан эш бирүчеләрдән дә тәкъдимнәр көтеп калабыз.

Үзәккә эш сорап мөрәҗәгать итүче үсмерләр бар икән инде. Аларга хезмәтләре өчен мәшгульлек үзәгеннән 1275 сум матди ярдәм һәм эш бирүчеләрдән эшләгән сәгатьләреннән чыгып түләү каралган.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

### ЧЫГАРЫЛЫШЛАР ФӘННӘР САЙЛЫЙ

1 февральгә кадәр районның 331 чыгарылышы БДИ тапшыру фәннәрен сайларга тиеш.

Район мәгариф бүлегеннән хәбәр итүләренчә, чыгарылышлардан гаризалар кабул итү 25 гыйнварда тәгәлләнә. БДИларны алдан тапшыру этабы 23 марттан 24 апрельгәчә узачак. Төп чор – 25 май-26 июнь. Имтиханнарны бирә алмаучылар аларны яңабаштан сентябрь аенда махсуслаштырылган үзәкләрдә тапшырачак. Быел бездә имтиханнар бары тик бер пунктта – шәһәрнең 3нче урта мәктәбендә генә узачак.

### СӘНГАТЬ МӘКТӘБЕНДӘ МАСТЕР-КЛАССЛАР

Кичә Балалар сәнгать мәктәбендә методик ярдәм көне иде. Ф.Яруллин исемендәге Әлмәт музыка көллиятеннән 8 педагог көн дәвамында мәктәп укучыларына һәм педагогларына мастер-классlар, ачык дәресләр бирделәр.

### ДИПЛОМАНТ БУЛГАННАР


Азнакайда узган “Сандугач сайрар илем” балалар иҗаты төбәк фестиваленнән Балалар сәнгать мәктәбе укучылары дипломант булып кайттылар. “Вокал” номинациясендә Самира Шәяхмәтова (укытучысы Ольга Гришина) һәм Дарья Вахрушина (Роза Әхмәтҗанова) фестивальдә 4нче урын алдылар.

**Зилия ӘКСАНОВА**

2015 – ПАРКЛАР ҺӘМ СКВЕРЛАР ЕЛЫ

# Ниһаять, паркларга да чират җитте

Агымдагы ел, ниһаять, Парклар һәм скверлар елы шигаре астында үтәчәк. Ниһаять, диюебез тикмәгә түгел: шәһәрнең авырткан җирләренең берсе бу. Озак еллар Нурлат бер генә ял паркы да булмаган төбәк хәлендә яшәде бит. Аннан шәһәр паркын яңарту барган берничә ел эчендә нурлатлыларның ачулы сүзләрен байтак ишетергә туры килде. Әмма булмас, дип өметсезлеккә төшкән нурлатлылар хәзер үзләре дә уңайсызланадыр: шәһәр паркы торгызылды, акрынлап ул бәйрәмнәр үзәгенә әверелеп килә, елдан-ел аттракционнарга байый бара. Әмма бит әле Нурлатта кул тиюне көткән күпме кече парклар һәм скверлар барлыгын да онытмыйк. Узган ел шәһәр базары янындагы шундый ярымташландык паркны торгызып булмасмы, дип без дә талпынып караган идек хәтта. Чөнки барган бер шәһәрдә, аеруча Мамадышта шундый кадерләп, тәрбияләп тотылган скверларга бик кызыгып кайткан идек. Тик эшебез, финанс ныгытуы ала алмаганлыктан, территорияне чистарту һәм чәчәкләр утыртудан узмады. Аның каравы, "Бердәм Россия" партиясе башлангыч оешмасы секретаре Татьяна Фадеевнаның шикәрчеләр бистәсендә Дуслык паркын торгызырга алынуы республика дәрәҗәсендә дә хуплау тапты, анысына да сөенәек. Авторның ТР Икътисад министрлыгы линиясе буенча социаль проектлар конкурсында откан 580 мең сум акчасы үзләштерелгән инде.




БАЗАР ЯНЫНДАГЫ СКВЕР ДА ЯҢАРТЫЛАЧАК

– Сумма октябрь аенда кереп, аны үзләштерүгә 2 ай гына вакыт бирелгән иде,–ди Татьяна Зиновьевна. – Алда кышкы салкыннар торуга карамастан, без төзелеш эшләрен, коймалар тотуны башкарып өлгерә алдык. Чиратта паркны җиһазлау, милли элементлар белән бизәү һәм яшелләндерү эшләре кала. Анысына апрельдә, көннәр җылынгач тотынырбыз дип торабыз.

– Бүленгән средстволар үзләштерелгәч, нинди акчага исәп тотасыз?

– Район җитәкчелеге ниятеннән аңлавыбызча, республика тарафыннан максатчан бүленгән суммадан да ярдәм булырга охшый. Диаспоралар, милли берләшмәләр, химаячеләр, волонтерлар да читтә калмас дип уйлыйбыз. Чөнки бу парк дуслык хакына хезмәт итәчәк бит. Ярдәм булыр, дип ышанабыз, чөнки моңа кадәргә эшләрне башкаруда без аларның кызыксынуын һәм аңлавын, ярдәмен тоярга өлгердек инде.

Татьяна Зиновьевна әйтүенчә, аны быел май айларында тапшыру күздә тотыла икән. Зур нәрсә булачак бу. Ә шәһәрнең архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигы Наталья Крайнова эшнең бер парк белән генә тәгәлләнмәячәген дә әйтеп шатландырды.

– Быел Парклар һәм скверлар елы кысаларында районга республикадан 15 миллион сум акча бүлеп биреләчәк, ТРның Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына программа һәм смета юлланылачак, – диде баш архитектор.

Наталья Александровна әйтүенчә, бу уңайдан район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин җитәкчелегендә эшче төркем оештырылган, чаралар планы кабул ителгән. Анда озакка сузмыйча башкарыласы эшләр дә билгеләнгән

– Болар–парклар һәм скверларга инвентаризация үткәрү, җир участокларын кадастр учетына кую, әлбәттә. Кызганычка каршы, әлегә бер шәһәр паркы гына теркәлү стадиясендә, калганнары гади генә әйткәндә, хуҗасызлар.

Ә әлеге исемлеккә кайсы парклар һәм скверлар кертелгән соң?

Наталья Александровна аларны якынча атап чыкты: исемлеккә Сәлимҗанов урамында базар янәшәсендәге сквер, шикәр заводы каршындагы Медведский паркын торгызу һәм Дуслык паркын ахырынача җиһазлау кертелә икән. Болардан тыш, шәһәрнең яңа микрорайоннарының берсендә Җиңү паркы дип исемләп, яңа паркка нигез салу да күздә тотыла. Шул рәвешле, шәһәр бер ел эчендә 4 заманча парклы булып куярга планлаштыра.

– Әлбәттә, парк һәм сквер зоналары тагы да бар, һәм аларга да акрынлап кул җитәр дип уйлыйбыз, – ди баш архитектор безнең сорауга каршы. – Иң мөһиме, бу эш урыныннан кузгала.

Еллык планга килгәндә, анда паркларны торгызудан тыш, Бөтенроссия, республика һәм район күләмендәге акцияләрдә катнашу, халыкта экологик культура тәрбияләү ниятеннән бердәм экологик дәресләр үткәрү, күргәзмәләр оештыру кебек чаралар да кертелгән. Нурлатлыларның моңарчы да "Үз агачыңны утырт", "Татарстанның чиста урманнары", "Урманнар көне", "Парклар маршы", "Бөтенроссия экологик шимбә өмәсе" һ.б. чараларда катнашу тәҗрибәсе бар инде, аларны агымдагы елда тагы да масштаблырак итү бурычы куелган. Чаралар, әлбәттә, шәһәргә генә түгел, авылларга да кагыла. Һәр авылда диярлек кече парк зоналары булдыру, аларны тәртиптә тоту быелдан башкарыласы эшләр исәбендә. Инде хәбәр иткәнебезчә, агымдагы елда районда 18600 төп яшь үсенте утырту, аны карап үстерү күздә тотыла. Гомумән, табигать, яшелләндерү темасы көнүзәктә булачак. Билгеле, агымдагы елның матур чараларын без дә бик рәхәтләнеп яктыртырга әзер. "Кеше һәм табигать" республика журналистлар конкурсында катнашып, җирле мәгълүмат чаралары болай да урыннар алып торалар бит.

Кыскасы, Парк һәм скверлар елы шәһәргә генә түгел, тулаем районга заманча ял урыннары, яшел зоналар һәм шуннан чыгып экологик иминлек нигезе булган чиста һава бүләк итәргә тиеш. Әлбәттә, халыкның ук тырышлыгы белән. Үзебезгә хезмәт итәсе матурлык һәм уңайлык тудыруга һәркем үз өлешен кертәсенә шикләнмибез!

Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА

ХАЛЫК ҖЫЕННАРЫ

# Проблемалар игътибарсыз калмый

**Районда халык җыеннары Биккол һәм Фома авыл җирлекләреннән башланып китте. Быелдан очрашуларда авыл җирлекләре башлыклары алдагы җыеннарда күтәрелгән һәр сорауның ничек хәл ителүе турында да хисап тота – бу исә авыллар халкы күтәргән бер генә мәсьәлә да игътибарсыз калмый дигән сүз.**

САН

**Фома авыл җирлегендә демографик хәл кискен тора: 2013 елда 3 бала туып, 15 кеше вафат булган булса, 2014тә нибары 2 сабый дөньяга килгән, 14 кеше үлгән.**

Әнә, Фома авыл җирлегендә узган ел башында үткәрелгән җыенда халыктан юлларның торышына бәйле сораулар күп кергән иде. Быел авыл җирлеге башлыгы Ирек Шәрәфетдинов:

- Фермерларны юллы итү республика программасы буенча 1100 метр, мәктәпкә кадәргә 250 метр арада юл салынды, - дип сөенеп хәбәр итте. Авыл җирлеге башлыгы быел авылда участок ветеринария пункты ачылуын, халыкның уртак тырышлыгы һәм җирле хуҗалык ярдәме белән авыл зираты коймаларын тулысынча алмаштырулары да уңай үзгәрешләр буларак билгеләп үтте. Монда авылның имам-хатыйбы Таһир ага Хәсәнов башлап йөргән икән.

Узган ел авыл җыенында күтәрелгән тагы бер көнүзәк мәсьәлә – мәктәпкә капиталь ремонт та үтәлү стадиясендә, биредә инде түбә, тәрәзәләрне алмаштыру эшләре алып барыла.

Үзгәрешләр шактый булса да, авылда проблемалы мәсьәләләр дә кала бирә әле. Әнә, авыл җирлеге Советы депутаты, җирле фермер Минтаһир Шаһиәхмәтов яңа юлны саклап тотасы иде, дип борчыла. Фермер хуҗалыгы юлыннан урам очына кадәр 200 метрлар чамасы гына юл ясалмый калган икән, материаллар табып шуны сузып бетерәсе иде, дип тәкъдим итә фермер. Халык исә Минтаһир Шаһиәхмәтовның авылның үләт базын яңарту, күлләрне тирәнәйтү, басуга чүпле тирес чыгарып ташлауга кагылышлы проблемаларны күтәрүен дә хуплап каршы алды. Очрашуда катнашкан җирле "Сөләйманов Ә.И" крестьян-фермер хуҗалыгы җитәкчесе Ирек Хәйдәрҗанова адресланган сораулар да бар иде. Алар нигездә авылда җирләрнең чикләре бозылу һәм кыр эшләрен авыл халкының терлек-туарына зыян китермәслек итеп башкаруга кагылышлы иде. Пай җирләре өчен бирелә торган шикәр комын терлек азыгы, нигездә фуражга алмаштырып булмасмы, дигән тәкъдим белән чыгучылар да булды.

- Авылның тормыш-көнкүреше өчен борчылып, аны яхшыртырга тырышуыгыз бик яхшы, - дип билгеләп үтте




ФОМАДАН ХӘЛИМ ХӘСӘНШИННЫ ПАЙ ҖИРЛӘРЕ ӨЧЕН АРЕНДА ТҮЛӘВЕ МӘСЬӘЛӘСЕ БОРЧЫЙ

очрашуда катнашкан район башлыгы Равил Кузюров һәм: – Илдә финанс тотрыксызлыгы булуга карамастан, бер генә дәүләти һәм социаль программа да туктатылмый, алар буенча эш шулай ук дәвам иттереләчәк, – диде. Шунда ук ул район буенча алда торган бурычларга да тукталды, сәнгать паркы булдырып, яңа җитештерү мәйданчыклары ачу нияте белән уртаклашты. Ә бу район икътисадын үстерү, яңа эш урыннары булдыру ягыннан мөһим.

Халык җыены традиция буенча юбилярларны, авыл тормышында актив катнашучыларны, "Төзек йорт" бәйгесе җиңүчеләрен котлаулар белән тәмамланды. Очрашу исә район һәм шәһәрнең барлык оешма-предприятиеләре җитәкчеләре катнашында үтте.

Лилия МӨБАРӘКШИНА

# МАНЗАРА

ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ

## Күңелләрне пакьләндерүче бәйрәм

**23 декабрьдән башлап районыбыз мәчетләрендә Мөхәммәд пәйгамбәрнең туган көненә һәм Рабигыль-әүвәл аена багышлап Мәүлид кичәләре узды.**




"СЕРДӘШ" АНСАМБЛЕ ЧЫГЫШЫН ДА ТАМАШАЧЫ ҖЫЛЫ КАБУЛ ИТТЕ

Дини чараларга йомгак шәһәр Мәдәният сараенда тулы зал һәм мәртәбәле кунаклар катнашында ясалды. Район күләмендә дини бәйрәм өченче ел рәттән зурлап билгеләп үтелә. Быел ул Болгарадагы Ак мәчет имам-хатыйбы Руслан хәзрәт Фәхретдиновның Коръән аятьләре укуыннан башланып китте.

Район башлыгы Равил Кузюров үз чыгышында күп гасырлык традицияләрнең Нурлатта шулай матур итеп билгеләп үтелүенә басым ясады.

– Мәүлид – Мөхәммәд пәйгамбәргә хөрмәт белдерүче олы бәйрәм. Бу Мөхәммәд пәйгамбәрне олылау, кешеләр белән аралашу, аларга Коръән сүрәләре, догалар җиткерү өчен искиткеч мөмкинлек, - диде район башлыгы. – Районыбызның дин әһелләренә барлык мәчетләрдә матур эшләр алып барганнары өчен рәхмәт.

Район мөселманнарын бәйрәм белән котлаган район мөхтәсибе Айрат хәзрәт Әюпов бу бәйрәмнең мөһимлегенә басым ясады һәм соңгы вакытта дөньяда барган гыйбрәтле вакыйгаларга да тукталды.

- Без, мөселманнар, экстремизмның барлык формаларына каршыбыз! - диде ул әлеге темага дәлилләр китереп. – Ә дини чараларны шулай халык җыеп зурлап үткәрү дини традицияләрне киләчәк буынга җиткерү өчен эшләнә. Шөкер, елыбыз күтәренке кәефтә уза. Бабаларыбыздан калган гореф-гадәтләрне кайтару ягыннан да зур эшләр башкарылды. Агымдагы елыбыз да вакыйгаларга бай булачак. Дин галимнәре елында чыгышы белән районнан булган атаклы дин шәхесе Әхмәтзәки Сафиуллинга багышланган зур чара планлаштырабыз.

Бәйрәмдә чыгыш ясаган мәртәбәле кунак - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин дин кардәшләребезгә мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның котлау - сәламнәрен җиткерде. Якташыбыз, "Мөселман календаре" авторы, журналист Фәния Хуҗахмәтнең, запастагы полковник, Нурлатның почетлы гражданины Идеал Галәветдинов һәм башка кунакларның чыгышы да Мәүлиднең асылы хакында булды.

Чарада Татарстан Республикасы Президенты эшләре идарәсенең гомуми бүлек мөдире Руслан Мәрданшинның да катнашуы дини мәсьәләләргә хөкүмәтнең игътибарын тагын бер кат ассызыклады.

Бәйрәмгә чакырылган кунаклар мөнәҗәтләр, салаватлар, Коръән аятьләре тыңлап хозурланды. Бу көнне мәчет имамнары гына түгел, районыбыз үзешчәннәре, "Сердәш" ансамбле һәм Балалар сәнгать мәктәбе укучылары катнашында бай программа тәкъдим ителде. Бәйрәмдә азан тавышы да яңгырады, тәҗвид белән Коръән дә укылды, онытыла башлаган бәет-мөнәҗәтләр белән берррәттән якташыбыз Фәүзия Мөхәммәтованың махсус Мәүлид бәйрәменә язылган яңа җыры да җырланды. Мөхәммәт пәйгамбәрнең тормышы, миссиясе турында вәгазьләр тыңлау, салаватлар әйтеп, аның шәфәгатен өмет итү традициясен нурлатлылар алга таба да дәвам итәргә җыена. Ә быелгы бәйрәм дога кылып тәмамланды.

**Зилия ӘКСАНОВА**

ГАББАС ГЫЙМАТДИНОВНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН

## "Ахмак белән булышма!"

**Габбас Кыямовичның минем һәм редакциянең башка хезмәткәрләре өчен дә гыйбрәтле киңәш-нәсыйхәте гомеремә хәтергә сеңеп калды.**

Бу вакыйга 1994 еллардарак килеп чыкты. Без газетаның чираттагы санын чыгару өстендә эшли идек һәм беренче биткә Ульянов исемендәге колхозның данлыклы сыер савучысы, Ленин ордены кавалеры Зәйнәп апа Кәримованың фотосурәтен куйдык. Фото астындагы текст, ягъни клише асты, кечкенә, әмма бай эчтәлекле иде. Зәйнәп апаның һәркемгә мәгълүм казанышларыннан тыш, мин аның "КПССта 50 ел" дигән күкрәк билгесенә ия булуын да искә алдым. Һәм менә шул билге белән матавык килеп чыкты да инде!

Журналист эше һәрчак шулай бит инде: четреклелекләр вак-төякләрне исәпкә алмаудан килеп туа. Миңа я колхозга, я булмаса райкомга шалтыратып төгәлләштерергә кирәк иде. Әммә мин кемнең-кемнең, ә менә Зәйнәп апаның бу бүләкка лаек икәнлегенә тамчы да шикләнмәгән идем шул. Тик соңрак ачыкланганча, Зәйнәп апаның партия стажы 50 елга ук тартмаганлыгы билгеле булды.

Ике-өч көн узгач, безнең рус дубляжы кабинетына кулына "Дуслык" тоткан бик ачулы бер укучыбыз бәреп диярлек килеп керде (этик ниятләрдән аның фамилиясен курсәтмим).

– Сезнең монда хата киткән, сез Зәйнәп Кәримова "КПССта 50 ел" билгесе белән бүләкләнгән, дип дөрес әйтмәгәнсез! – дип бусагадан ук тавыш күтәрде кунагыбыз.

Аның тупаслыгы һәм кычкыруы яхшылап сөйләшүгә өмет уятырлык түгел иде.

– Ә ни өчен бу Сезнең ачуыгызны чыгарды соң әле?

– Белмәсәгез – белегез, әлеге билгене күптән түгел миңа тапшырганнар иде, ә һич тә Кәримовага түгел. Аңа бу бүләкне алырга ирешергә кирәк әле! Бу хәбәрегезгә кире кагу бирмәсәгез, райкомга барам!

Кыскасы, безнең арада ызгыш булды. Һәм мин, кызып китеп, аның бу билгене кабинеттан-кабинетка күчеп, йомшак урындыкларда гына утырып, куштанланып алуын, ә Зәйнәп Кәримовага мондый бүләк гомеренең дистәләрчә елын фермада уздырганы һәм савым буенча һәрвакытта да алдынгы торганы өчен булса да бирелергә тиеш, аның исеме республикага да таралган, дидем. Бу бик ярсулы яңгырады, әлбәттә, әмма дөрес иде!

Аңлашыла ки, мондый аңлашулардан соң, кунагыбыз, хәзер моны райкомның беренче секретарена җиткерәм, дип янады да ишекне шапылдатып ябып чыгып китте. Курыктым, дип әйтә алмыйм, әмма әлеге кеше белән үземне тотышыма ачуым бик озак тынгылык бирмәде – район газетачысы эшендә бу сирәк хәл, һәрвакытта да кешеләр белән аралашканда алтын урталыкны табарга тырышасың. Ә монда... матур килеп чыкмады, әлбәттә, хәер, җәнҗаллы кунак алдында гафу үтенергә омтылып карадым үзе, әмма аның берни дә ишетәсе килми иде инде. Шулай итеп, миңа райкомга, "кәләмгә" чакыруны көтәргә генә калды.

Бу вакыйгадан соң яхшы ук вакыт узган иде инде, редакция мәшәкатьләре белән теге бәрелеш онытылып та бетте диярлек. Әммә һич көтмәгәндә "райком", төгәлрәге беренче секретарь Габбас Кыям улы Гыйматдинов редакциягә үзе килеп керде. Соңрак билгеле булганча, үзенең 70 яшьлек юбилее уңаеннан сугылуы булган икән. Һәм менә ул, мөхәррир Рәис Җамалиев озатуында туп-туры рус бүлегенә, ягъни безнең янга юл алды.

Эш бүлмәбезнең ишек төбендә мәһабәт гәүдәле Габбас Кыямович пәйда булгач, минем ни дәрәҗәдә гаҗәпләнүемне күз алдына китерә аласыздыр! Өстәвенә, ул перчаткаларын да салмыйча, туп-туры миңа таба килде. Һәм мин, аның үтәли күз карашы йогынтысында, исәнләшергә дип урынымнан бераз күтәрелдем, бөтенесе күз алдында әрләвенә дә әзер идем инде, тик шулчак Габбас Кыямовичның көчле итеп... кулымны кысуын тойдым.

– Теге әрәмтамакны урынына утыртып дөрес эшләгәнсең бит син, афәрин! Тик киләчәктә исеңдә тот: кызма, сүзләреңне уйламыйча уңга-сулга чәчмә – аларны һәрчак сиңа каршы да кулланырга мөмкиннәр бит. Пушкин әйткәнчә, ахмак белән булышма!

**Дания ТЯМАЕВА,**
Казан, гыйнвар, 2014 ел

ТЕРЛЕКЧЕЛЕКТӘ – КЫШЛАТУ




ИРИНА ИМУКОВА – ХУҖАЛЫКНЫҢ ТӘҖРИБӘЛЕ СЫЕР САВУЧЫЛАРЫННАН

## Күңелгә якын һөнәр

**Еллар үтү белән терлекчелектә мул продукция алу ысуллары да үзгәреш кичереп тора, әмма сыер савучы хезмәтенә карата таләпләр шул килеш кала.**

"Агромир" җәмгыятенең Егоркино бүлекчәсе сыер савучысы Ирина Имукова фермага моннан 30 ел элек, 18 яшендә килгән булган.

- Ул чагында кул хезмәте күбрәк кулланыла иде, - дип беренче елларын исенә төшерә Ирина Анатольевна. - Савылган сөтне бидоннар белән ташый идек. Хәзер исә һәр бүлектә диярлек сөтүткәргеч бар. Дөрес, сыерлар саны артыграк – ул чагында 20-25 булса, бүгенге көндә 48 сыер савам.

48 баш сыерны көнгә өч тапкыр саварга кирәк. Шуңа да бүлекчәдә сыер савучыларның эш көне иртәнге 4тән үк башлана. Кичке савым тәмамланганчы, кичке 7 җитә. Сыер савучыларның хезмәтләре исә саву белән генә чикләнми – үз төркемнәрендәге сөтлебикәләрнең чисталыгын кайгырту, савым аппаратларын тәртиптә тоту, фураж өләшү һәм башка эшләр дә алар җилкәсендә.

- Безнең хезмәт хакы күпме сөт савуыбызга бәйле, - ди Ирина Имукова. – Шуңа да һәркайсыбыз мул сөт саву өчен тырыша, ә моңа барлык таләпләрне үтәгәндә генә ирешеп була.

Шуңа да хуҗалыкта терлекчелеккә, аеруча продуктлылыкны арттыруга зур игътибар бирә башлауларын да сыер савучылар бик сөенеп кабул иткәннәр. Көнбагыш түбе, катлаулы углеводлар кебек өстәмәләр кулланыла башлагач, сөтләр дә артты, диләр. Димәк, тагы да тырышыбрак эшләр өчен стимул да бар.

Ә Ирина Анатольевна эшкә генә түгел, үзенең зур гаиләсен һәм хуҗалыгын кайгыртып торырга да өлгерә. Хуҗалыкта тегермәнче булып эшләүче тормыш иптәше Александр Николаевич белән 4 бала тәрбияләп үстергәннәр. Үзе исә моннан 3 дистә ел элек нәкъ менә фермага эшкә килүенә үкенми – эше авыр булса да, күңеленә якын. Ә бу барыннан да мөһимрәк.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

ПРОКУРАТУРАДА

## Хисап тоту мәҗбүри

**Нурлат шәһәр прокуратурасы коррупция законын бозу фактына чик куйды, әлеге факт дәүләт милкен файдалануга кагылышлы иде.**

Прокуратура Нурлат район үзәк хастаханәсендә коррупциягә каршы тору законнарының үтәлешен тикшерде. Нәтиҗәдә, ЦРБда закон бозу очраклары билгеле булды, хастаханә үзләренә беркетелгән дәүләт милкен 2012-2013 елларда файдалану турында сайтка хисап урнаштырмаган. Тикшерүнең нәтиҗәләре буенча, Нурлат шәһәр прокуратурасы баш табиб исеменә представление чыгарды. Хәзерге вакытта ул карау стадиясендә.

**Евгений СЕРГЕЕВ,**
Нурлат шәһәр прокуратурасы

БЕЗНЕҢ ӘҢГӘМӘ

# Салымны кадастр бәясе билгели

**Агымдагы елда күчемсез милек ияләрен чираттагы үзгәрешләр көтә. Бу хакта безгә РФ Федераль салым службасының ТР буенча 12нче районара салым инспекциясе баш дәүләт инспекторы Ләйсән МӨЛЕКОВА сөйләде.**



**– Ләйсән Шамилевна, башта узган елга нәтиҗәләр ясагыз әле.**

– Нурлат районында салым исәбендә 844 оешма, 534 филиал һәм 1086 шәхси эшмәкәр бар. Узган ел район һәм шәһәрнең салым түләүчеләре барлык дәрәҗә бюджет системасына 1 млрд. сумга якын акча түләгәннәр. Инспекциянең салым законнары нормаларын үтәүләрне тикшерү җәһәтеннән уздырган контроль чаралары ярдәмендә җирле бюджетка өстәмә рәвештә 6 млн. сумнан артыграк акча кертелгән.

**– Бу ел башыннан нинди яңалыклар кертелде соң?**

– 2015 елның 1 гыйнваренннан физик затларның милкенә салымны формалаштыру һәм исәпләп чыгару процессы үзгәрде. Хәзер салым милекнең инвентарьлаштыру түгел ә, кадастр бәясе буенча исәпләнәчәк. Кадастр бәясен санап чыгарганда, күчемсез милекнең урыны, аның мәйданы, сегменты, төзелү елы кебек факторлар исәпкә алына. Димәк, кадастр бәясе объектның базар бәясен төгәлрәк чагылдыра диген сүз. Инвентарьлаштыру бәясе, кагыйдә буларак, базар бәясеннән күпкә түбән. Салым тотып калулары да каралган. Салым базасын билгеләгәндә объектның кадастр бәясе кими: фатир буенча – аның гомуми мәйданының 20 кв. метры бәясе күләменә, бүлмәләргә – бүлмәнең гомуми мәйданының 10 кв. метры, торак йортның гомуми мәйданының 50 кв. метры бәясенә. Составына бер генә булса да торак бина кергән бердәм күчемсез милек комплексына салым базасы 1 млн. сумга киметелгән кадастр бәясе буларак билгеләнә. Муниципаль берәмлекләр күрсәтелгән тотып калуларны арттырырга хокуклы.

**– Милек салымы түләүдә кемнәр ташламага ия?**

– Салым түләүдән тулысынча СССР һәм РФ Геройлары, Бөек Ватан сугышы, гражданнар сугышы, сугышчан хәрәкәтләр ветераннары, "әфганчылар", элеккеге хәрбиләр, хәрбиләрнең туендырučысын югалткан гаилә әгъзалары, 1 һәм 2 группа инвалидлар, балачактан инвалидлар, пенсионерлар, "чернобыльчеләр" азат ителә. Шулай ук ЛПХлар, дача хуҗалыгы, бакчачылык, индивидуаль торак төзелеше территорияләрендәге мәйданнары 50 кв метрдан да артмаган хуҗалык биналары һәм корылмаларына салым түләнми. Моннан тыш, иҗади остаханәләр, ательеларга, дәүләти булмаган музейлар, галереялар, китапханәләр оештыру өчен файдаланылучы торак биналарга да салым кагылмый. Салым ташламалары һәр төрдән түләүченең үз сайлавы буенча бары тик берәр объектка гына бирелә.

**– Бу ташламаларны ничек алырга була?**

– Аларны алу өчен ташламага хокукны раслаучы документлар белән бергә объектны сайлау турындагы уведомление китерергә кирәк. Гаризалар агымдагы елның 1 ноябренә кадәр тапшырылырга тиеш. Инде ташламалар бирелгән объектларга яңадан гаризалар бирү кирәкми. Уведомление китерелмәсә, салым органы һәр төрдән бер объект буенча ташламаны үзе бирә, монда салым суммасы максималь исәпләнелә. Әмма бу очракта шунысын да белеп торыгыз: кадастр бәясе 300 млн. сумнан артып киткән объектларга ташлама бирелми.

**МӘГЪЛҮМАТ**

**Үз күчемсез объектларыгызның кадастр бәясен ТР Җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгы сайтында да белергә була: www.mzio.tatarstan.ru/Результаты государственной кадастровой оценки. Моның өчен бары тик объектның кадастр паспорты мәгълүматларындагы кадастр номерын гына күрсәтергә кирәк.**

**– Почта аша килгән уведомлениеләрдән тыш, исәпләүләр турындагы мәгълүматны тагы нинди ысул белән белеп була?**

– Гамәлдәге ставкалар, милеккә салым буенча ташламалар, исәпләнелгән салым суммасы турында Россия ФНСы сайтындагы электрон сервислар аша белергә мөмкин, шулар аша ук салымны түләргә дә була. Моннан тыш, әлеге сервис ярдәмендә салымнар буенча бурычларны белә, расчетларны контрольдә тота, салым органнарына шәхсән үзегез килми генә дә мөрәҗәгать итә аласыз.

– Әңгәмәгез өчен рәхмәт!

**Светлана ИГНАТЬЕВА** сөйләште

СПОРТ

## Чаңгычылар команда туплады

**Район укучыларының чаңгы буенча җыелма командасы тупланды. Моның өчен узган атнада Богдашкинода сайлап алу ярышлары үткәрелде.**

– 4 яшь категориясендә иң көчле чаңгычыларны ачыкладык. Якын араларда бу җыелма команда Татарстан беренчелегендә һәм укучыларның VII Спартакиадасында да Нурлат данын яклаячак, – ди балалар-үсмерләр спорт мәктәбе тренеры, ярышларның баш хөкемдары Иван Белов.

Шул рәвешле, сайлап алу ярышларында укытучы-тренерлар Иван Белов, Владимир Шугаев, Валерий Трофимов, Любовь Живодерова, Вячеслав Герасимов, Ольга Евсеева, Александр Ендиряков шәкертләре матур күрсәткечләргә ирештеләр. Нәтиҗәдә, Алексей Михеев, Дарья Белова, Лиза Тахтаманова, Зарина Митрофанова, Максим Сандимиров, Анна Ефимова, Илья Алексашкин һәм Виталий Кашкаров үз яшь категорияләрендә беренче урыннарны алдылар. Чәршәмбе көнне чаңгычыларның җыелма командасы Зәйгә, Спартакиадага китте, ул якшәмбегә кадәр дәвам итәчәк.

## Келәмдә тыйнаклык килешми

**Нурлат балалар-үсмерләр спорт мәктәбенең билбау көрәшчеләре командасы Әлкидәге турнирдан, хуҗалардан гына калышып, икенче урын алып кайтты. Бу хакта ДЮСШ тренеры, команданың җитәкчесе Расих Сәмигуллин хәбәр итте.**

– Әлки районында "Восток-Агро" җәмгыяте оештырган ачык беренчелек иде ул. Анда биш районнан көчле көрәшчеләр катнашты. Кунак булсак та, әлләни тыйнаклык күрсәтмәдек: безнең дүрт спортчыбыз чемпион титулы яулап кайтты. Болар – Иглайдан Илсөя Садриева, Чулпаннан Вилдан Сәетов белән Тимур Хәснетдинов һәм Еларүдан Илья Алексашкин, – диде Расих Каимович.

## Өч бәйрәмгә уртак бәйге

**Районның көчле шахматчылары Яңа ел, Раштуа һәм Искечә Яңа ел бәйрәмнәре хөрмәтенә уртак турнир уздырдылар.**

Әлеге бәйге шахматчыларның үз клубында үтте һәм анда 12 кеше катнашты. Нәтиҗәдә, I урынны Ринат Миннебаев яулады. Григорий Ермолаев – II, Михаил Безруков III урыннарны алдылар.

**Илназ МӨБАРӘКШИН**

ГАДӘТТӘН ТЫШ

## Минутлар хәл иткән

**31 декабрьдә кичке 7ләр тирәсендә ведомстводан тыш сак бүлегенә Нурлаттагы бер предприятиенең сак постыннан "авария" хәвефле сигнализациясенең эшләп китүе турында хәбәр керә.**

ОВОның тоткарлау төркеме вакыйга урынына килеп җиткәч, сак будкасына ут кабуына, бинаның көчле төтенгә күмелүенә тап була. Будканың тәрәзәсе аша ОВО хезмәткәрләре кушеткада йоклап ятучы сакчыны күреп алалар. Тиз арада бу хакта хәбәр тиешле службаларга юллана. Полиция өлкән сержанты Ф.Ефимов янгын сагы подразделениесен көтеп вакыт уздырмаска һәм утта калган ир-атны коткарырга кирәк, дигән карарга килә. Полиция өлкән сержанты А.Михайлов белән бергәләп алар ишектән бинаның эченә үтәләр. Хасил булган уентыкка һава тула, пыскып баручы ут көчәеп китә, бина мизгел эчендә ялкынга күмелә, әмма хезмәткәрләр сакчыны уттан алып чыга алалар. Ул 1951 елгы Нурлат кешесе була. Урынга килеп җиткән медицина хезмәткәрләре зыян күрүченең аякларында һәм битендә 1, 2нче дәрәҗәдәге термик пешүләрне ачыкладылар. Хәзерге вакытта әлеге ир-атның гомеренә инде берни янамый.

**Илдус ТӘМАЕВ,**
МВД бүлегенең полиция начальнигы урынбасары

ҖӘМГЫЯТЬ

# Илен үз иткәч, тарих-телен дә бел

**Россиядә эшләргә теләүче чит ил кешеләре 2015 елның 1 гыйнваренннан башлап рус теле, Россия тарихы һәм Россия Федерациясе законнары нигезләре буенча имтихан тапшырырга тиеш.**

Моннан башка алар эшкә урнашырга мөмкинлек бирүче патент һәм вакытлыча яшәү рөхсәтен ала алмаячак. Татарстандагы мигрантларга Яр Чаллы, Түбән Кама һәм Алабугада имтиханнар тапшыру мөмкинлеге тудырылган. Россия буенча андый хезмәт күрсәтүче фәнни үзәкләрнең саны 400гә җитә. Билгеле булганча, әлеге яңалыклар 2014 елда "Россия Федерациясендә чит ил гражданнарының хокукый халәте турында"гы Федераль законга үзгәрешләр кертелү нәтиҗәсендә барлыкка килде. Яңалыклар хакында УФМСның Нурлат районы бүлеге начальнигы, эчке служба капитаны **ЗӨЛФИРӘ ХИСМӘТУЛЛИНА** сөйләде.

– Әлеге үзгәрешләр соңгы елларда Россиягә ташкын булып агылган мигрантларга җирле җәмгыять тормышына яраклашырга ярдәм итү максатыннан эшләнгән, - ди Зөлфирә Әмировна. – Яңа елдан башлап чит ил кешеләреннән рус телен, Россия тарихын һәм РФ законнарын белү турындагы сертификат, белем турындагы документ таләп ителә. Бары шул документлар нигезендә патентлар биреләчәк. Узган ел бу категория гражданнарга 87 патент бирелгән иде.

Патент 1 ел гамәлдә булачак һәм әлеге 87 кешегә яңа закон буенча имтихан биреп торуның кирәге юк икән.

**– Кулында сертификаты булмыйча эшкә килеп урнашкан мигрантка да, аны эшкә алган эш бирүчегә дә нинди дә булса җаваплылык каралганмы?**

– Әлбәттә, сертификатсыз эшләүче һәм яшәүче мигрантка закон бозган өчен 2 мең сум, ә эшкә алган юридик затка 25 мең сумнан башлап штраф яный.

2014 елда Нурлатта 616 мигрант теркәлгән. Аларның күпчелеген Үзбәкстан, Таҗикстан һәм Украина гражданнары тәшкил иткән. Соңгылары 83кә җиткән. "Кунаклар" сатучы, төзүче эшенә урнашу нияте белән килгәннәр. Алар яңа таләпләр кергәнче эшкә урнашып өлгергәннәр. Яңалык миграция хәрәкәтенең кыскаруына китерергә мөмкин, диләр белгечләр. Моңа кадәр арзанлы хакка эшче көч алырга күнеккән эш бирүчеләргә дә авырлыклар туры килер, мөгаен, үзебезнекеләргә дә эш урыны күбрәк калыр, дип әйтүчеләр дә бар. Әмма ни генә булмасын, яңа закон гамәлгә кергәннән бирле УФМСның Нурлат бүлегендә 3 чит ил гражданы консультация алырга өлгергән инде.

Узган ел 255 чит ил кешесе миграцион исәптән төшерелгән, ә 19 чит ил кешесе вакытлыча яшәүгә рөхсәт алган. Шул чорда миграция бүлеге 20 чит ил гражданинына яшәү кәгазе (вид на жительство) биргән. Нигездә алар пенсия яшендәгеләр һәм яңа туган сабыйлар икән.


Яңа елдан кертелгән үзгәрешләр дәүләт пошлиналары артуына да китергән. Чит ил, биометрик, Россия паспортлары, гражданлык, яшәү кәгазе алу, паспортны югалту яисә бозган очракта яңабаштан ясату өчен хәзер шактый сумма чыгарып саласы икән.

**Зилия ӘКСАНОВА**

# Что будет с ценами на продукты?

## Отвечает депутат Госсовета РТ Вадим Махеев

**Недавно продовольственная сфера столкнулась с серьезными испытаниями – сначала были так напугавшие всех санкции, затем в стране начался неудержимый рост цен на продукты. Многие опасаются, что цены и дальше продолжат рваться вверх, а некоторые товары исчезнут с полок. Мы расспросили основателя и владельца сети гипермаркетов, депутата Госсовета РТ Вадима Махеева, что будет с ценами на продукты в гипермаркетах ЭССЕН.**



На встречах с жителями города, по горячей линии и просто знакомые покупатели ко мне часто обращаются с вопросами, будет ли повышение цен в гипермаркетах ЭССЕН, подорожают ли социальные товары, ожидается ли дефицит товара на полках.

Да, действительно, тенденция повышения цен существует. Это связано с колебанием курсов валют, санкциями на импортные товары. Но для нас всегда была важной и первостепенной задачей **работа над низкими ценами.** И в нынешней ситуации мы максимально стараемся сдерживать их рост, чтобы каждый покупатель мог по-прежнему видеть на своем столе привычную продуктовую корзину. Для нас это задача номер один. Сейчас люди особенно тщательно планируют свой бюджет. Мы видим, что приходя в магазин, наши клиенты совершают покупки по заранее спланированным спискам. И понимаем, что ситуация непростая, поэтому прикладываем больше усилий, чтобы **не допустить роста цен** на продукты. Проводим переговоры с поставщиками, и стараемся добиваться от них адекватных цен. Порой, чтобы получить желаемый результат, приходится тратить много сил и времени, но мы понимаем, что это наша социальная ответственность перед нашими клиентами.

Каждый покупатель сейчас может заметить, что с полки пропадает его любимый продукт. Мы хотим, чтобы наши клиенты понимали, что это – явление временное и связано оно с тем, что сейчас некоторые производители пытаются играть ценами, необоснованно их поднимая. В таких случаях мы просто вынуждены приостанавливать поставку товара, на время ведения переговоров с поставщиками, до момента пока не будут получены **обоснованные цены для наших клиентов.** Также одним из решений проблемы служит замещение импортных товаров на товары местных производителей и фермеров. Это позволяет предложить клиентам тот же широкий ассортимент товаров, которые они покупали каждый день для своей семьи. К примеру, в качестве товара, который может позволить себе каждый, мы предлагаем покупателям собственную торговую марку. Цена на товары собственной торговой марки ниже цены аналогичного товара. Ассортимент большой – тут и макаронные изделия, и консервы, и чистящие средства, и другие товары. Например, подсолнечное масло «Амика» сейчас стоит 56,40, тогда как, в среднем, стоимость подсолнечного масла других производителей составляет 71 рубль. Такая низкая цена достигается за счет отсутствия затрат на рекламу для продвижения продукции.

Мы приняли решение, что заморозим цены на социально значимые товары на уровне 2014 года. Данные цены будут установлены на срок до 31 марта 2015 г. в гипермаркете ЭССЕН г. Нурлат.

Вадим Махеев считает, что главная задача «ЭССЕН» – **сделать продуктовую корзину каждого человека вкусной и доступной.** Молоко, мясо, яйца, творог, крупы, мука, масло – без всего этого невозможно представить поход в магазин. Очень важно, чтобы товары, входящие в социальную корзину были доступны для всех.

Постоянное внимание к запросам покупателей, **честные цены** и постоянно обновляющийся ассортимент качественных товаров позволяют компании «ЭССЕН» оставаться одной из самых крупных компаний в Приволжском Федеральном округе и завоевывать доверие покупателей Чувашии, Удмуртии, Башкирии и Марий Эл.

### Список товаров

| Наименование | Стоимость, руб. |
|---|---|
| Творог обезжиренный «Вкусняев», 250 г | 37,50 |
| Карамель «Клубника со сливками», Объединенные кондитеры. 100 г | 15,30 |
| Консервы говядина, «Главпродукт», тушеная, ГОСТ, 325 г | 98,00 |
| Хлеб «Дачный», 750 г, Чистополь | 29,30 |
| Бумага туалетная, 1 шт | 5,00 |
| Молоко «Российское», питьевое пастеризованное, 2,5 %, «Вкусняево», 900 г | 28,50 |
| Масло «Крестьянское», сливочное, 72,5 %, 180 г | 26,90 |
| Хлеб «Белый» из пшеничной муки, 600 г, Вита | 18,30 |
| Хлеб «Дарницкий», подовый, 600 г, Вита | 14,10 |
| Кефир обезжиренный, «Вкусняев», 430 г | 14,90 |
| Макароны перья, 1 кг, Рахимов | 30,00 |

Реклама

ХӘТЕР

# Вакыт белән сыналган якутлар

**Әлмәт шәһәрендә яшәүче легендар якташыбыз Зәкия Туешевага 29 нчы декабрьдә 95 яшь тулды. Чаткыдай чәчрәп,балкып торган бу ханымга ул яшьне биреп тә булмый әле.**

Гасырга якын гомер юлы үтелгән. Гыйбрәтле дә, әрнүле дә, бәхетле дә елларның хатирәсе аның күңелендә әле бүген дә яши.

Самара өлкәсе Заһид авылыннан Коръәнне һәм аның тәрҗемәсен яттан белгән Хафиз Туешевны хәзерге Нурлат районы Яңа Әлмәт авылына муллалык эшенә җибәрәләр. Белемле мулланы бередә яратмаучылар да була. Дөнья бит!

- Авыл тулы надан халык иде, гарәп, төрек, рус телләрен камил белүче әтине кулак мулла дип укытуыннан, муллалыктан читләштерделәр, - дип хатирәләргә кереп китте ул.

Нечкә күңелле, саф йөрәкле, кешеләрне яратучы самими кыз бала мулла кызы дигән ярлык астында үзенең якты киләчәгенә өметләнгән, илгә кирәкле кеше булачагына чын күңелдән ышанган.

Илгә кирәкле булуын күп тапкырлар исбатлады инде ул . Беренчесе һәм ин авыры сугыш чорында булгандыр. Нәни Зәкия укый-яза белә, спектакльләрдә суфлер вазифасын үти. Авыл яшьләренә шулай ярдәм итә.

- Урамга көндез чыгарга курка идек. Кичләрен караңгы урамда еракта якты ут янган тәрәзәләр янына киләм. Анда көлешкән кешеләрне күреп исем китеп торам. Бу клуб булган икән. Шыпырт кына мич артына кереп посам да, түрдәге авыл яшьләренә карыйм.

- Булмады инде, таралыйк! Суфлер килмәде. Аннан башка кабатлап булмый!

Әсәрне укый белүче юк.

- Мин укый беләм! - дип кычкырганымны сизми дә калдым. Шулай итеп, суфлер булып киттем. Мәктәптә укып булмый. Мулла балаларын кертмәделәр. Миңа клуб бер юаныч булды. Ә дәресләрне безгә өйдә әти укытты.




ЛЕГЕНДАР ШӘХЕС БЕЛӘН ОЧРАШУ МИЗГЕЛЛӘРЕ СИЗЕЛМИ ДӘ ҮТЕП КИТТЕ

Асыл нәсел баласы югалмый. Казанга театр училищесына укырга керә. Сугыш башлангач, үз теләге белән шәфкать туташы булып фронтның алгы сызыгында була.

- Мәскәүдән килгән табиб, атказанган хирург Иван Кравченконың ассистенты булдым, меңләгән солдатка гомер бүләк итте ул. Бик кырыс иде, 12 шәр сәгать операция өстәле янында эшләде. Аз гына ялда кая егылсам, шунда йоклый идем. Иван Иванович үзе дә: "Балакай,сезгә сугыш күрми яшәргә иде дә бит", - дип әрни иде. Ул миңа яңа исем белән Зоки дип дәшә иде. Өзелгән кул-аяклар, яшь-яшь егетләрнең кулда үлеп китүләре, кан һәм үлем арасы. Әтидән өйрәнгән догаларны укып күзләрен йомдыра идем, кулымда татар егетләренең үлүләре бигрәкләр дә әрнү була иде.

Шул кечкенә генә татар кызының күкрәгендә "Кызыл Йолдыз" ордены, "Польшаны азат иткән өчен" медале шул чакта ук балкый. Орден - медальләре гарасатлы, авыр сугыш елларының сүзсез шаһитлары булып костюмында тезелеп тора.

- Яшәлмәгән дә кебек, – дип тагын сөйләп китә Зәкия ханым. - Яшьлек шуның өчен дә яшьлек бит ул. Бар авырлыкны, иңнәрне баскан хәсрәт- кайгыны да "киләчәктә бар да яхшы булыр" дип кагып кына төшергән еллар.

Әлмәт шәһәре драма театрына эшкә килеп, режиссер дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән, бар гомерен, назын, вакытын шул театрга сарыф иткән Зәкия ханымның көләчлегенә, искиткеч зыялылыгына, эрудициясенә, бай юмор хисенә сокланып истәлекләр дөньясында хозурланып утырам.

- Балачак бишегем - Яңа Әлмәт авылына, аның эчкерсез, хезмәт сөючән халкына рәхмәтлемен. 13 ел гомерем шулар арасында үткән бит, - дип әңгәмәне дәвам итә Зәкия ханым.

Ирексездән үземне уйлыйм. Мин дә бу авылда оя кордым, балалар үстердем, мәктәптә эшләдем, укучыларны музейларда йөрттем, күршеләремне яраттым, авыл кешеләреннән бары тик яхшы мөнәсәбәт кенә күрдем. Зәкия ханым йөргән авыл сукмакларында 24 ел гомерем үтелгән. Авылдашларымны мин хәзер дә хөрмәт белән искә алам.

- Авыл сәхнәсе мине олы театрга алып килде. Табиб булу мөмкинлеге бар иде. Мин театрны сайладым. Үзем сайлаган язмыш белән яшәдем, мин язмышымнан канәгать ,–диде ул.

Легендага тиң гомер үткән бу сөйкемле ханымга ихтирамым тагын да арткан хәлдә саубуллаштым.

- Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан парадта катнашырга хыялланам әле, яшәп булса инде,-дип елмайды Зәкия ханым мине озатканда.

Тагын очрашулар насыйп булсын дип аерылыштык...

**Фирдәвес ГАРИФУЛЛИНА,**
Нурлат шәһәре

